Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының
"Монай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең
гражданнар җыены карары

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монай авыл җирлеге составына керүче Монай авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 28 ноябреннән № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монай авыл җирлеге составына керүче Монай авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең Монай авылы яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә, I-II төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышы тыл хезмәтчәннәре, көндезге уку формалары студентларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Бакча урамы буенча юлны чистарту;
2) Чистарту корылмалары өчен насос, компрессор сатып алу;
3) Видеокүзәтү өчен җайланма сатып алу һәм урнаштыру;
4) Юлларны асфальтлау эшләрен проектлау шартнамәсе өчен түләү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Монай авылы мәгълүмат стендларында урнаштырырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendelevsk.tatar.ru «Монай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Монай авыл җирлеге Башлыгы Р.М.Кириллов